Мөслим гимназиясе укучылары газетасы

МӨСЛИМ ГИМНАЗИЯСЕ

# ТЫЛСЫМ+

№5 (73)

Февраль, 2026 нчы ел

2026 ГОД ЕДИНСТВА НАРОДОВ РОССИИ

2026 ГОД ВОИНСКОЙ И ТРУДОВОЙ ДОБЛЕСТИ
ХӘРБИ БАТЫРЛЫК ҺӘМ ХЕЗМӘТ ФИДАКАРЬЛЕГЕ ЕЛЫ

Бу санда

*Фән олимпиадалары көндәлеге* 2

*Уңыш формуласы* 2

*Җырга әйләнгән гомер* 3

*Җәлил атналыгы* 3

*23 нче февраль - Ватанны саклаучылар көне* 4

*Нәрсә ул батырлык?* 4

## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ



### "Киләчәк йолдызлары" исемле республика бәйгесенә йомгак ясалды

Казан шәһәрендә «Күпмәдәниятлелектән гомумроссия бердәмлегенә: өстәмә белем бирү миссиясе» темасына багышланган XV республикакүләм Алиш укулары узды.

Анда "Киләчәк йолдызлары" исемле республика бәйгесенә йомгак ясалды.

Мөслим гимназиясенең инглиз теле укытучысы, 6 нчы в сыйныфы җитәкчесе Гөлшат Мөхәммәтҗанова әлеге бәйгенең "Иң яхшы сыйныф җитәкчесе" номинациясендә җиңү яулады.



### Ел укучысы - 2025

13 февральдә Мөслим гимназиясе базасында «Ел укучысы - 2025» муниципаль конкурсының финал туры узды.

4 нче а сыйныфы укучысы Хәбибуллина Алия (укытучысы – Ермолаева Э.С.), барлык биремнәрне дә уңышлы үтәп, 2 нче урынга лаек булды. 4 нче б сыйныфы укучысы Солтанова Сылу (укытучысы – Мирзасалихова Г.Ш.) номинациядә җиңү яулады.

Конкурста катнашучыларның барысын да котлыйбыз!



### Күмәк көч - тау күчерә

Мөслим гимназиясендә махсус хәрби операциядә катнашучылар өчен гуманитар ярдәм җыю буенча акция узды.

Акциядә укытучылар коллективы, техник хезмәткәрләр, укучылар, аларның әти-әниләре катнашты.

Хәрби операциядә катнашучы һәркем безне, безнең илне яклый. Шуңа күрә андагы һәркемгә булышу - безнең бурыч. Игелекле ярдәм дәвамлы булсын, ярдәм җыюда катнашкан һәркемгә саваплары кайтсын!





### Сәламәт тәндә – сәламәт акыл

2 февральдән 6 февральгә кадәр Пермь шәһәрендә армрестлинг буенча Идел буе федераль округы чемпионаты һәм Беренчелеге узды. Ярышларда 13 төбәктән 500 дән артык спортчы катнашты.

Татарстан Республикасы җыелма командасы составында гимназия укучылары да катнашты: 7 нче б сыйныфы укучысы Бариев Ислам, 10 нчы б сыйныфыннан Зиннурова Илзирә, 11 нче сыйныфтан Әхмәдуллин Айзат чемпион булып беренче урынны яуладылар. Алар буш вакытларында "Яшьлек" спорт мәктәбенең армрестлинг секциясендә шөгыльләнәләр.

7 нче а сыйныфы укучысы Сәетгалиев Искәндәр «Сабантуй» журналы призына Көрәш буенча Татарстан Республикасы Беренчелегендә катнашып, 2 нче урынны яулады.


Укучыларыбыз белән горурланабыз һәм алга таба җиңүләр телибез!

# ФӘН ОЛИМПИАДАЛАРЫ КӨНДӘЛЕГЕ

**Россиякүләм һәм Республикакүләм фән олимпиадалары дәвам итә.**

«Олимпка юл» республика олимпиадасының математика фәне буенча йомгаклау этабында 11 нче сыйныф укучысы Әмир Дәүләтшин (укытучысы Госсамова Р.С.), инглиз теленнән 10 нчы а сыйныфыннан Галимова Эльза (укытучысы – Бакирова Г.Р.), рус телле балалар өчен татар теленнән узган республика олимпиадасында 6 нчы б сыйныфы укучысы **Руслан Семенов**, 8 нче а сыйныфыннан **Ирина Асманова** (укытучылары - Ямалова Г.Ф.), рус мәктәбендә татар төркеме укучылары өчен татар теленнән узган республика олимпиадасында 9 нчы б сыйныфы укучысы **Айназ Галимова** (укытучысы – Авзалова З.З.), татар мәктәпләрендә белем алучы укучылар өчен татар теленнән, татар әдәбиятыннан узган республика олимпиадасында 11 нче сыйныфтан **Хәсәнова Йолдыз** (укытучысы – Мирзамуратова Г.М.), рус теленнән һәм рус әдәбиятыннан узган республика олимпиадасында **Айгильдина Зарина** (укытучысы – Хәйруллина Ч.А.), физик тәрбия фәненнән 9 нчы а сыйныфы укучысы **Хафизова Әминә** (укытучысы – Шәйхетдинов Д.Г.), Ватанны саклау һәм иминлек нигезләре фәненнән 11 нче сыйныфтан **Әхмәдуллин Айзат** (укытучысы – Галиев З.З.) призёр булдылар. Укучыларыбызны һәм укытучыларыбызны котлыйбыз!




















# УҢЫШ ФОРМУЛАСЫ




“Тылсым+” газетасы, 11 нче сыйныф укучысы, бернечә ел рәттән республикакүләм туган (татар) теле һәм әдәбияты фәннәреннән олимпиада призеры булган Хәсәнова Йолдызга бернечә сорау белән мөрәҗәгать итте.

***- Йолдыз, синең яраткан язучыларың бармы? Булса кемнәр?***

- Мин Гаяз Исхакый, Нәбирә Гыйматдинова, Аяз Гыйләҗев әсәрләрен яратып укыйм.

***- Нинди жанрларда китаплар укырга яратасың?***

- Күбрәк хикәя-повестьлар укырга яратам.

***- Сиңа китап уку нинди очракларда булыша?***

- Китап уку иншалар язганда булыша, чөнки күбрәк укыган саен кешедә сүз байлыгы арта. Иншаны җөенке җөмләләр белән матур яңгырашлы итеп язарга ярдәм итә.

***- Быелгы уку елында туган (татар) тел һәм әдәбияттан республика олимпиадасында призер булдың. Призлы урынга чыгу өчен ничек әзерләнергә кирәк? Гимназия укучыларына нинди киңәшләр бирер идең?***

- Минем уйлавымча, иң беренче чиратта укучы олимпиадада үзе теләп катнашырга, аның үзенең урын алу теләге булырга тиеш, чөнки шул вакытта гына ул яхшылап әзерләнә.

Минем шуны әйтәсем килә: безнең барыбызның да мөмкинлекләребез бар, бары тик үзеңә максат куеп, тырышырга гына кирәк. "Тырышкан табар, ташка кадак кагар", дигән мәкаль дә бар. Димәк, тырышкан кеше бөтен максатларына да ирешә ала.

***- Йолдыз, әңгәмәң өчен зур рәхмәт! ЕГЭларыңны әйбәт кенә тапшырып, киләчәктә үзең теләгән уку йортында укырга язсын сиңа.***

***Әңгәмәдәш Замалова Зәринә***

# ҖЫРГА ӘЙЛӘНГӘН ГОМЕР




## Без белмәгән Муса

***Муса Җәлилнең тууына 120 ел***

Җәлил шахмат уйнарга яраткан, җиңгән очракларда бала кебек куанган, ә җиңелгәндә, үзенә “грошмейстер” дип әйтә торган булган.

Шагыйрь, язудан тыш, музыканы да яраткан, аның хәтта үз мандолинасы булган, ул пианино алу турында хыялланган.

Матур җырлаган.

Шәп чаңгычы булган.

Шагыйрь тоткынлыкта 791 көн була.

1956 нчы елның 2 нче февралендә сугышта күрсәткән тиңдәшсез ныклыгы һәм батырлыгы өчен **Советлар Союзы Герое** исеме бирелә.

“Моабит дәфтәрләре” циклы **Ленин премиясенә** лаек була.

Бу ике югары бүләкне берьюлы алган бердәнбер әдип.

# ҖӘЛИЛ АТНАЛЫГЫ







Һәр милләттә исеме телгә алынуга ук ихтирам уята торган шәхесләр була. Муса Җәлил - әнә шундыйлардан. Бу исемне телгә алуга, аның кабатланмас шигырьләре һәм күпләр өчен кыюлык һәм батырлык үрнәге булган көрәше һәм эшчәнлеге күз алдына килеп баса. Ул - ялкынлы шигырьләр язган шагыйрь дә, илнең азатлыгы өчен көрәшкән курку белмәс, үлемне ирләрчә каршылаган каһарман да.

Гимназиядә Муса Җәлилнең тууына 120 ел тулу уңаеннан, туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучысы Авзалова Зилә Зөфәровна «Җәлил эзләре буйлап» дип аталган квест-уен үткәрде. Квест-уенда 7, 8 нче сыйныф укучылары катнашты. Зилә Зөфәровна шагыйрьнең тормыш юлы, иҗаты, Бөек Ватан сугышындагы батырлыгы турында сөйләде. Укучылар Җәлил турында фильм карадылар. Командаларга бүленеп, станцияләрдә шагыйрь иҗаты буенча биремнәр эшләделәр.

5-6 нчы сыйныфлар өчен татар теле һәм әдәбияты укытучысы Солтанова Г.М. "Әдәби кунак бүлмәсе" исеме астында чара уздырды. Укучылар шагыйрьнең тормышы, иҗаты белән таныштылар. Икенче өлештә укучылар викторина сорауларына җавап бирделәр.

"Салют сиңа, Муса Җәлил!" шигырь конкурсында башлангыч сыйныф укучылары, ярыша-ярыша, Җәлил шигырьләрен ятлап, сәхнәдән сөйләделәр. 64 укучы катнашып, күбесе 1, 2, 3 урыннарга лаек булдылар.

Югары сыйныфлар да читтә калмады, әдәби музыкаль кичәдә Муса Җәлилнең иҗаты белән таныштылар, аның сүзләренә язылган җырлар җырладылар. Музыка укытучысы Гөлнур Әзһәмовна Муса Җәлилнең җырларын өйрәтүгә зур көч куйды.

> ***“Дөньяда шулай итеп яшәргә кирәк: үлгәннән соң да үлмәслек булсын...”***
>
> ***Муса Җәлил***

Герой-шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 120 ел тулу гимназиядә үз югарылыгында уздырылды.

### Яз өмәсе

Без кояшка килдек өмәгә,
Кардан-боздан җирне арчырга.
Вакыт инде кышка үләргә,
Яз батырга юлны ачырга.

Кыш кергәннән бирле капкадан,
Җир җитәрлек күрде «явызлык».
Багор белән ваклап, ваткалап,
Җибәриек кышны агызып.

Елгаларны япты, бикләде,
Дулкыннарны итте ирексез,
Чишмәләрнең юлын чикләде,
Болыннарны итте күрексез.

Ул киптерде нәфис гөлләрне,
Бакчалардан куды кошларны,
Сызганыек, дуслар, җиңнәрне,
Ломга алыйк әрсез «дошман»ны.

.....
Боз астыннан чыксын елгалар,
Дулкынланып ташып аксыннар,
Торкылдашып күктән торналар
Көмеш күлгә кире кайтсыннар.

***Муса Җәлил***

# 23 НЧЕ ФЕВРАЛЬ - ВАТАННЫ САКЛАУЧЫЛАР КӨНЕ




***Хөрмәтле гимназия ир-егетләре, укучы егетләр!***

*Ватанны саклаучылар көне – батырлык, намус һәм кыюлык көне белән ихластан ир-егетләребезне котлыйбыз.*

*Бүгенге бәйрәм көчле рухлылык, ир-егетләрнең кыюлык, намус һәм абруй шикелле сыйфатларга ия булуларын тагын бер кат раслый торган тантана.*

*Сезгә һәм якыннарыгызга тыныч күк йөзе, ныклы сәламәтлек, бәхет-шатлык, рухи һәм матди байлык, һәр эшегездә бары тик уңышлар гына телибез.*

*Кадерле ир-егетләребез, батырлыгыгыз, җаваплылыгыгыз һәм ышанычлылыгыгыз өчен рәхмәт. Без сезнең белән горурланабыз!*

***"Тылсым+" газетасы редколлегиясе***

# НӘРСӘ УЛ БАТЫРЛЫК?

***Бу сорауга Мөслим гимназиясенең 6 нчы б сыйныфы укучыларының җаваплары түбәндәгечә:***

***

Нәрсә ул батырлык? Бу сорауга җавапны сез беләсезме? Менә мин шул турыда сөйлим әле!

Мин, Гыйздуллин Рүзәл, Мөслим гимназиясенең 6 Б сыйныфы укучысы. "Батырлык нәрсә ул?"- дигән сорауга җавап эзлим. "Берәр батырлык эшлә, белерсең, " диләр миңа.

Минем Фәнзил һәм Илназ исемле абыйларым бар. Алар зурлар инде. Берсенә утыз, икенчесенә егерме җиде яшь.

Илназ абыем махсус хәрби операциядә катнаша. Ул 2022 нче елда мобилизацияләнде. Башта алар Казан шәһәрендә өйрәнүләрдә булдылар. Әнием янына барып та кайтты, аннары Украинага җибәрделәр. Абыем авыр яраланып, озак кына безнең янга кайтып торды. Яралары төзәлгәч Ватан алдындагы бурычын үтәргә кабат китте. Нинди генә авыр задание булса да, куркыныч чакларда да түзәргә кирәк дип сөйли ул.

Дошманга каршы көрәштә үзен аямаганы, Ватаныбызга тугры булганы өчен абыемны дәүләт бүләге "Жуков" медале, "Сугыштагы казанышлары өчен" медале һәм "Штурм өчен" күкрәк билгесе белән бүләкләделәр.

Бүгенге көндә Илназ абыем кыска вакытлы ялга кайтты. Ул өйдә булганда миңа бик рәхәт. Батырлык турында да сөйләшәбез. Абыем бик күп мисаллар китерә. Ут эчендә калган иптәшләрен коткарганнарын кабат-кабат сөйләтергә яратам.

Ватан сакчыларының шушындый үрнәге минем өчен зур батырлык!

***Гыйздуллин Рүзәл***

***

Минемчә, батырлык ул – кешенең яхшы сыйфаты. Кеше якыннарын, туган илен, ярдәмгә мохтаҗ кешеләрне яклау өчен төрле адымнар ясарга мөмкин. Батыр кешегә үз-үзен аямау хас. Әсәрләрдә без сугыш вакыты, тыныч тормыш батырлары турында күп укыйбыз. Муса Җәлил, Илдар Маннанов, Рөстәм Нәбиев кебек геройлар турында күп язмалар укыйбыз, тапшырулар тыңлыйбыз.

**Ватанны саклаучылар көне уңаеннан**

Хәзер махсус хәрби операциядә безнең якташларыбыз, районнашларыбыз катнаша. Күптән түгел без Ф.Гыймалтдиновның "Үлемнән бер адым алдарак" әсәрен укыдык. Анда Илнур Хаертдинов исемле абыйның "Урал" мотоциклында яралыларны сугыш кырыннан алып чыгуы турында язылган.

Тыныч тормышта да янгыннан, суга батудан коткаручылар турында күп ишетеп беләбез.

Ләкин бар кеше дә батыр була алмый. Моның өчен тәвәккәл, курку белмәс булырга, шулай ук физик яктан көчле булырга, спорт белән шөгыльләнеп көч тупларга кирәк. Телефонда күп утырып, батырлык турында кинолар карап кына батыр булып булмый.

Һәр кеше үзендә яхшы сыйфатлар булдырырга тиеш.

***Сәләхов Ранель***

**Гимназиябезнең асыл егетләре**



**Җиңүче команда**



ТЫЛСЫМ+
Гыйнвар, 2026 нчы ел
№5 (73)
*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

**Баш мөхәррир:** Солтанова Г.М.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.

**Мөхәррир:** Замалова Зәринә
**Корректорлар:** Хәйруллина Диләрә
**Корреспондентлар:** Насырова Мәрьям, Фәхрәзиева Алинә
**Дизайнер:** Мостафина Рәйлә
**Компьютерда җыючылар:** Вагыйзов Айзат, Сәләмов Наил

***2014 нче елдан айга бер тапкыр нәшер ителә***

**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym
**Электрон адрес:** tilsim2014@yandex.ru
**Формат:** А4 (А3)
**Тираж:** 100